ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ    КАРАР

19.09.2018    г.Мензелинск    № 1057

2018-2019 елларның көзге-кышкы чорында Минзәлә муниципаль район территорисендәге объектларның һәм торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын көчәйтү турында

Янгын чыгу куркынычы булган көзге-кышкы чорда янгын куркынычсызлыгын көчәйтү, район оешмалары һәм предприятиеләре ирекле янгын сагының матди-техник базасын ныгыту максатларында, 21.12.1994 елда кабул ителгән "Янгын куркынычсызлыгы турында"гы №69-ФЗ Федераль законы нигезендә, 06.10.2003 елда кабул ителгән "Россия Федерациясе җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары" №131-ФЗ Федераль законын кулланып, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2018-2019 елларның көзге-кышкы чорында Минзәлә муниципаль район территорисендәге производство объектларын һәм торак пунктларны әзерләү буенча чараларның беркетелгән планын расларга (Кушымта №1)

2. 2018 елның 01 октябренә кадәр срокта предприятие, оешма җитәкчеләренә, район авыл җирлеге башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- янгын-техник минимум программалары буенча операторларны, мич ягучыларны, электрикларны, эретеп ябыштыручыларны укытуны оештыру;

- объектларны, аеруча балалар, укыту, мәдәни-күңел ачу учреждениеләрен, терлекчелек биналарын тәүлек буе сак белән тәэмин итү, шулай ук объектларда җаваплы затларның кизү торуын оештыру;

- җылытылган янгын деполарында һәм ягыла торган гаражларда һәм боксларда булган янгын техникасын урнаштыру, шулай ук әлеге биналарны телефон һәм радио элемтәсе чаралары белән тәэмин итү;

- биналарга, корылмаларга илтүче, янгынга каршы су белән тәэмин ителеш юлларына керү юлларын ачу һәм аларны вакытында җылыту, чистарту һәм биналардан экакуацияләү юлларының ачык булуын тәэмин итү.

3. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ДУнең Татарстан Республикасы буенча Актаныш һәм Минзәлә муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге

һәм профилактик эш буенча районара бүлегенә тәкъдим итәргә (Тимерханов А.Ф.);

- муниципаль берәмлекләрнең торак фондын тикшерүне оештыру һәм уздыру, беренче чиратта янгын куркынычсызлыгы буенча аеруча начар булган, янгынга каршы тору түбән булган йортларга, тулай торакларга һәм кунакханәләргә аеруча игътибар итеп, аңлату эшләре алып барып, нәтиҗәләрне гражданнарның җыеннарында тикшерергә;

- торак пунктлар торак фондының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә уздырылган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне басма массакүләм мәгълүмат чараларында, теле- һәм радиоканалларда яктыртуны оештыру;

- ягу системасын, электр җиһазларын һәм электр приборларын эксплуатацияләгәндә халыкка янгын куркынычсызлыгы чараларын аңлатуны активлаштыру. Көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларын җиткереп, янгыннарда оператив торыш турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештыру. Янгынга каршы тематикага агитация һәм пропаганда материалларын әзерләү буенча җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтергә һәм почта элемтәсе, торак оешмалары, халыкка социаль ярдәм күрсәтү хезмәткәрләре, ВДПО, милициянең участок уполномоченныйлары мөмкинлекләрен кулланып, аларны халыкка таратуны оештыру;

- Ростехнадзорның Татарстан Республикасы буенча технологик һәм экологик күзәтчелек буенча идарәсе һәм башка кызыксынган ведомстволар белән берлектә ягулык-энергетик комплекс предприятиеләрен (котельня, җылылык генерацияләүче җайланмалар һәм агрегатлар, подстанцияләр) тикшерүне оештыру;

- авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, “Энергонадзор” хезмәте һәм районның башка хезмәтләре белән берлектә халык күп була торган һәм тереклек тәэмин итү объектларының, авыл хуҗалыгы предприятиеләренең янгынга каршы торышына комиссия тикшерүен оештырырга һәм уздырырга;

4. “ФПСның Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряд” ФДКУ, 122 нче янгын коткару частенә (Губернаторов В.М.) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- торак пунктларда янгын-профилактика эшен уздыру өчен подразделениеләрнең шәхси составын, ирекле янгын сагы әгъзаларын җәлеп итәргә. Массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итеп һәм күрсәтелгән затлар яшәгән урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча тиешле чаралар кабул итеп күпбалалы гаиләләр, ялгыз картлар, имин булмаган гражданнар яшәгән урыннарны, билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар торган урыннарны тикшерүгә аеруча игътибар бирергә;

. – янгын гидрантларын тикшерергә;

- янгын техникасының һәм ДПОның эшкә әзерлеген тикшерергә;

5. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәр Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Ф.Ягафаровка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Г. Гатина

Кушымта 1
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
Җитәкчесе карарына
«19» 09 2018 ел. № 1057

# 2018-2019 елларның янгын чыгу куркынычы булган көзге-кышкы чорына янгыннар профилактикасы һәм районның производство объектларын һәм торак пунктларны әзерләү буенча чаралар
# ПЛАНЫ

| № п/п | Чараларның исемнәре | Уздыру срогы | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1 | Янгын куркынычы булган көзге-кышкы чорга әзерлек өлешендә икътисад тармагы объектларында һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүгә күзәтчелек буенча планлы (плансыз) чараларны исәпкә алып, күзәтчелек буенча чаралар планы белән тәңгәллеккә китерергә | 2018 елның октябрь-декабрь. | Предприятие, оешма җитәкчеләре, МОНД һәм ПР начальнигы |
| 2 | Ростехнадзорның Татарстан Республикасы буенча технологик һәм экологик күзәтчелек буенча идарәсе һәм башка кызыксынган ведомстволар белән берлектә ягулык-энергетик комплекс предприятиеләрен (котельня, җылылык генерацияләүче җайланмалар һәм агрегатлар, подстанцияләр) тикшерүне оештыру | 2018 елның октябре | ОАО «Коммунальные сети», начальник МОНД и ПР |
| 3 | Янгыннарны кисәтү максатларында торак фондында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау буенча айлык оештырырга һәм уздырырга. | октябрь 2018 года. | Авыл җирлекләре башлыклары, ФПСның Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряд” ФДКУ, 122 нче янгын коткару часте начальнигы, ЭЭБ начальнигы, МОНД һәм ПР начальнигы |
| 4 | Торак фондын һәм торак пунктларны янгыннан саклауны кутәүрү мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннарын һәм халык белән очрашуларны оештыру, җирле үзидарә җитәкчеләре биргән сорауларны карарга. | көзге-кышкы чор дәвамында | Авыл җирлекләре башлыклары, ФПСның Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряд” ФДКУ, 122 нче янгын коткару часте начальнигы, ЭЭБ начальнигы, МОНД һәм ПР начальнигы |
| 5 | Җылылык генерациясе җайланмаларына хезмәт күрсәтүче вазифаи затларны янгын-техник минимумы программалары буенча укытуны оештыру | 2018 ел, октябрь | «Коммуналь челтәрләр» ААҖ, МОНД и ПР начальнигы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Янгын сагы подразделениеләренең килеп җитү норматив вакытыннан чыккан торак пунктларда ирекле янгын сагы булдыру буенча чаралар комплексын башкару | 2018 ел, октябрь – ноябрь | Авыл җирлекләре башлыклары, ФПСның Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряд" ФДКУ, 122 нче янгын коткару часте начальнигы, , МОНД һәм ПР начальнигы |
| 7 | Торак пунктларда һәм икътисад тармаклары объектларында янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының төзек булуына, янгын сулыкларын җылытуга, су чыганакларына килү юлларын җайлауга, ачык сулыкларда туңмый торган бәкеләр булдыруга, суэтем башнясы җиһазларын янгын автомобильләренә су алу өчен, шул исәптән кышкы чорда су алу өчен җиһазлауга ирешергә. | октябрь – ноябрь 2018 года. | Авыл җирлекләре башлыклары, оешма һәм предприятие җитәкчләре, ФПСның Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряд" ФДКУ, 122 нче янгын коткару часте начальнигы, МОНД һәм ПР начальнигы |
| 8 | Яңа ел елкаларын һәм бәйрәм тантаналары уздырганда янгын-профилактик чаралар комплексын эшкәртергә һәм башкарырга. | 2018 ел, декабрь | ФПСның Татарстан Республикасы буенча 15 нче отряд" ФДКУ, 122 нче янгын коткару часте начальнигы, МОНД һәм ПР начальнигы МОНД и ПР |
| 9 | Массакүләм мәгълүмат чаралары белән берлектә янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау буенча оештыру чараларын әзерләргә һәм башкарырга. | 2018 ел, октябрь | Газета редакторы, МОНД и ПР начальнигы |
| 10 | Янгыннарны профилактикалау һәм кешеләр үлемен кисәтү проблемаларын даими рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртырга. | Көзге-кышкы чор дәвамында. | Газета редакторы, МОНД и ПР начальнигы |
| 11 | Янгыннарда кешеләр үлемен кисәтү буенча экспресс-мәгълүмат һәм янгын чыгу куркынычы булган көзге-кышкы чорда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында памятка әзерләргә. | 2018 ел, октябрь | МОНД и ПР начальнигы |